**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧЫПЧЫК**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422736, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Чыпчык авылы, Совет ур., 1

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЧЕПЧУГОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422736, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Чепчуги, ул. Советская,1

тел./факс 8(84365) 72-5-01, e-mail: Chep.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР**
**12 декабрь 2019 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 16**

## Чыпчык авыл җирлеге башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап тоту Тәртибен раслау турында”, 2019 елның 31 октябрендәге 13 номерлы Карарын гамәлдән чыгару турында

“Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында”, 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, “Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында”, 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның 1, 6 статьялары нигезләмәләре, “Ветеринария турында”, 1993 елның 14 маендагы 4979- I номерлы Россия Федерациясе Законының 3 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, санитар-эпидемиягә каршы чараларны норматив-хокукый җайга салу, шул исәптән сукбай этләрне тоту мәсьәләләре дә Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә кертелгән һәм җирле үзидарә органнары компетенциясенә кермәү сәбәпле, Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Чыпчык авыл җирлеге Башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап тоту Тәртибен раслау турында”, 2019 елның 31 октябрендәге 13 номерлы Карары белән расланган Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап тоту Тәртибен гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар бастырып чыгарган (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә

керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Чыпчык авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р.Җиһаншин